Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданнар А.Н. Болдырева һәм О.М. Серова шикаятьләренә бәйле рәвештә «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 12 пунктындагы өченче абзацының, 15 пунктының, 16 пунктындагы икенче абзацының һәм 17 пунктындагы өченче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2020 елның 29 апреле

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге

732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 12 пунктындагы өченче абзацының, 15 пунктының, 16 пунктындагы икенче абзацының һәм 17 пунктындагы өченче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданнар А.Н. Болдырева һәм О.М. Серова шикаятьләре сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Э.М. Мостафина мәгълүматын, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы юридик бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе Ф.М. Мөхәммәдиева, суд утырышына дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенечнамәсе буенча чакырылган белгеч — Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының торак сәясәте бүлеге башлыгы Н.К. Вильданова, суд утырышына чакырылган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты вәкиле — «Зеленодольск муниципаль районының Торак сәясәте департаменты» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе Н.Н. Минһаҗев аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданнар А.Н. Болдырева һәм О.М. Серова «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге

732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең (алга таба шулай ук — Кагыйдәләр) 12 пунктындагы өченче абзацы, 15 пункты, 16 пунктындагы икенче абзацы һәм 17 пунктындагы өченче абзацы белән үзләренең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләр белән мөрәҗәгать иттеләр.

Кагыйдәләрнең 12 пунктындагы өченче абзацы гражданның сертификат алуга хокукын таныган очракта, җирле үзидарә органы тарафыннан аны сертификат алу өчен гражданнар исемлекләренә кертү турында карар кабул ителүен күздә тота.

Кагыйдәләрнең 15 пункты нигезендә җирле үзидарә органнары ел саен, 1 октябрьгә кадәр, бу Кагыйдәләргә 1 нче кушымта нигезендә планлаштырыла торган елга гражданнар исемлекләрен формалаштыралар һәм аларны Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына кертәләр (беренче абзац) (алга таба шулай ук — Министрлык); гражданнар исемлекләре гражданнар җирле үзидарә органнарында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелган хронологик эзлеклелекне саклап формалаштырыла (икенче абзац).

Кагыйдәләрнең 16 пунктындагы икенче абзацы, планлаштырыла торган елга сертификатлар алу өчен гражданнарның җыелма исемлекләре Министрлык тарафыннан гражданнар җирле үзидарә органнарында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелган шул ук хронологик эзлеклелекне саклап формалаштырыла дип билгели.

Кагыйдәләрнең 17 пунктындагы өченче абзацы нигезендә сертификатлар алучы гражданнар һәм сертификат алу өчен резервка кертелгән гражданнар исемлекләре Министрлык тарафыннан гражданнар җирле үзидарә органнарында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелган хронологик эзлеклелекне саклап формалаштырыла.

Ике мөрәҗәгать итүченең дә күпбалалы (гражданка О.М. Серованың — биш баласы, гражданка А.Н. Болдыреваның — алты баласы) булган гаиләләре 2019 елда торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган һәм шикаять белдерелә торган Кагыйдәләр нигезендә сертификат алу хокукына ия гражданнар исемлегенә кертелгән. Гражданка О.М. Серова балаларының берсе — Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырудан интегүче инвалид.

Мөрәҗәгать итүчеләр күрсәткәнчә, дәгъва белдерелә торган нигезләмәләр буенча җирле үзидарә органнары да, шулай ук Министрлык та, гражданнар җирле үзидарә органнарында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә куелган хронологик эзлеклелекне саклап, сертификат алу максатында гражданнар исемлекләрен формалаштыра. Үзләренең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуны алар сертификатның торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләләргә бишенче бала туу чираты буенча түгел, ә аларны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую чираты буенча бирелүендә күрәләр. Мондый мөнәсәбәт булганда, алар фикеренчә, максаты — нәкъ менә биш һәм аннан күбрәк баласы булган һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне (алга таба шулай ук — күпбалалы гаиләләр) торак белән тәэмин итү буенча өстәмә ярдәм күрсәтү һәм, димәк, сертификат алу өчен чиратны билгеләгәндә төп критерий бишенче бала туу яки сертификат алу хокукына ия гаиләне тану датасы булырга тиешле шикаять белдерелә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының алдан билгеләнеше югала.

Гражданнар А.Н. Болдырева һәм О.М. Серова билгеләгәнчә, Кагыйдәләрдә мохтаҗлыкның, мәсәлән, гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган торак урынның гомуми мәйданы һәм бишенче бала туган вакытта гаиләнең керем дәрәҗәсе кебек өстәмә критерийлары каралмаган. Мөрәҗәгать итүчеләр санаганча, һәр гаиләнең факттагы яшәү шартлары аерыла һәм сертификат бирү турында карар кабул иткәндә алар шулай ук исәпкә алынырга

тиеш. Дәгъва белдерелә торган Кагыйдәләрдә шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләләр өчен чираттан тыш сертификат алу хокукы билгеләнмәгән.

Моннан тыш, үзенең шикаятенә өстәмә рәвештә Кагыйдәләрнең 12 пунктындагы өченче абзацының һәм 15 пунктындагы беренче абзацының конституциячеллеген дәгъвалап, гражданка О.М. Серова әлеге нормалар, килеп туган хокук куллану практикасыннан чыгып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан башта тиешле исемлекләргә кертү турында гариза тапшырылуга, аны карау нәтиҗәләре буенча гражданин сертификат алу хокукына ия дип танылуга карамастан, ел саен яңадан теркәлү узганда һәм торак урынына мохтаҗлыкны раслаганда дәүләт торак сертификатларын алучылар исемлегенә кертү турында кабат гариза бирү зарурлыгын күздә тоталар дип күрсәтә.

Гражданка О.М. Серова Кагыйдәләрнең 12 пунктындагы өченче абзацы һәм 15 пунктындагы беренче абзацы арасында каршылык күрә, чөнки беренче нигезләмә билгеләгәнчә, һәрвакыт, гражданның сертификат алуга хокукын таныган очракта, җирле үзидарә органы тарафыннан бер үк вакытта аны сертификат алу өчен гражданнар исемлекләренә кертү турында да карар кабул ителә, ә икенчесе — җирле үзидарә органнары тарафыннан ел саен, 1 октябрьгә кадәр, гражданнар исемлекләре формалаштырыла. Аның фикеренчә, гражданны сертификат алу өчен гражданнар исемлегенә кертү турындагы карарларның җирле үзидарә органнары тарафыннан ел саен 1 октябрьгә кадәр формалаштырыла торган гражданнар исемлегеннән ни белән аерылуы аңлашылмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүчеләр Татарстан Республикасы Конституция судыннан «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге

732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 12 пунктындагы өченче абзацын, 15 пунктын, 16 пунктындагы икенче абзацын һәм 17 пунктындагы өченче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 54 (беренче өлеш), 55 статьяларына туры килми дип тануны сорыйлар, алар нигезендә закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; гаилә, ана булу, ата булу, балачак һәм картлык дәүләт яклавында; дәүләт гаилә турында, ананың һәм баланың сәламәтлеген тәэмин итү һәм балаларны тәрбияләү турында кайгырта; һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән, туендыручысын югалткан очракта, балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә; һәркем торакка хокуклы; беркем дә торагыннан нигезсез мәхрүм ителә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар.

Кагыйдәләрнең 16 пунктындагы икенче абзацы һәм 17 пунктындагы өченче абзацы Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булганнар иде инде (2013 елның 10 июлендәге 54-П номерлы карар). Әмма әлеге нормалар күрсәтелгән эш буенча карап тикшерү предметы булып торган икән, торак сертификатын алганда, авыл җирендә яшәүче күпбалалы гаиләләргә карата, аларны бер үк хәлгә куеп, алар шәһәрдә яшәүче күпбалалы гаиләләргә өстенлекне күздә тотмаган. Моннан чыгып, гражданнар А.Н. Болдырева һәм О.М. Серова белдергән аспектта дәгъва белдерелә торган нигезләмәләрнең конституциячеллеген тикшерүдән баш тарту өчен нигезләр юк.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы өченче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, түбәндәгеләр әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар:

— Кагыйдәләрнең 12 пунктындагы өченче абзацы, аның нигезендә гражданның сертификат алуга хокукын таныган очракта, җирле үзидарә органы тарафыннан аны сертификат алу өчен гражданнар исемлекләренә кертү турында карар кабул ителә;

— Кагыйдәләрнең 15 пунктындагы беренче абзацы, аның нигезендә җирле үзидарә органнары ел саен, 1 октябрьгә кадәр, бу Кагыйдәләргә 1 нче кушымта нигезендә планлаштырыла торган елга гражданнар исемлекләрен формалаштыралар һәм аларны Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына кертәләр;

— Кагыйдәләрнең 15 пунктындагы икенче абзацы, 16 пунктындагы икенче абзацы һәм 17 пунктындагы өченче абзацы, җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы сертификатлар алучы гражданнар һәм сертификат алу өчен резервка кертелгән гражданнарның исемлекләрен гражданнарның бишенче бала туу вакытына яисә сертификат алу хокукын тану датасына бәйле түгел, ә гражданнар торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелган шул ук хронологик эзлеклелекне саклап формалаштырган өлешендә.

2. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны кабул итү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә кагылышлы мәсьәлә Татарстан Республикасы

Конституция судының берничә тапкыр тикшерү предметы булган иде, ул, Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләрен раслап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенә федераль һәм республика законнары нигезендә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, алар буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты социаль тәэминат өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша, Татарстан Республикасы территориясендә федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәү мәҗбүри булган карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара (2011 елның 5 октябрендәге 44-П номерлы, 2013 елның 10 июлендәге 54-П номерлы, 2019 елның 30 маендагы 83-П номерлы һәм 2019 елның 25 декабрендәге 87-П номерлы карарлар), дигән нәтиҗәгә килде. Татарстан Республикасы Конституция судының күрсәтелгән карарлары һәм аларда чагылдырылган хокукый позицияләр үз көчләрен саклый.

3. Татарстан Республикасын социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), Татарстан Республикасы Конституциясе шуны беркетә: гаилә, ана булу һәм балачак дәүләт яклавында, дәүләт гаилә турында, ананың һәм баланың сәламәтлеген тәэмин итү һәм балаларны тәрбияләү турында кайгырта (38 статья, беренче һәм өченче өлешләр); һәркемгә балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә (54 статья, беренче өлеш). Мәгънәләре буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясе, шул исәптән аның 7, 38 (1 өлеш) һәм 39 (1 өлеш) статьялары белән билгеләнгән.

Россия Федерациясе Конституция Суды карарларында билгеләп үтелгәнчә, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклауны Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагына кертеп

(72 статья, 1 өлешнең «ж» пункты), Россия Федерациясе Конституциясе гражданнарның теге яки бу категорияләренә бирелә торган мондый яклауның конкрет ысулларын һәм күләмнәрен билгеләми. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының аерым хокукы булып тора, ул Россия Федерациясе Конституциясенең 38 һәм 39 статьялары белән беркетелгән хокукларны гамәлгә ашыру гарантияләрен билгеләгәндә гаилә һәм балаларны социаль яклау чараларын, аларны дифференциацияләү критерийларын сайлап алуда, күрсәтелү шартларын һәм тәртибен регламентлаштыруда җитәрлек дәрәҗәдә ирекле эш итә; ул шулай ук аларның күрсәтелү формаларын (ысулларын) сайлап алырга һәм үзгәртергә хокуклы (2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы Карар, 2010 елның 9 ноябрендәге 1439-О-О номерлы Билгеләмә).

2011 елның 5 октябрендәге 44-П номерлы карарында Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгечә билгеләп үткән иде: күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен субсидияне түләүсез нигездә бирү рәвешендәге социаль ярдәм чарасы үзенең хокукый табигате буенча социаль тәэмин итүнең мәҗбүри төренә керми һәм, асылда, күрсәтелгән гаиләләрнең тормыш дәрәҗәсен яхшыртуның өстәмә алымы буларак билгеләнә. 2013 елның 10 июлендәге 54-П номерлы, 2019 елның 2 декабрендәге 87-П номерлы карарларында һәм 2011 елның 11 октябрендәге 13-О номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 36-О номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 37-О номерлы билгеләмәләрендә алар тарафыннан расланган әлеге хокукый позиция үз көчен саклый.

Шулай итеп, хокукый җайга салуны гамәлгә ашырганда, үзенә бирелгән вәкаләтләр кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты җитәрлек дәрәҗәдә ирекле карау мөмкинлегенә ия, шул ук вакытта ул чикләнмәгән түгел, ә конституциячел әһәмияттәге кыйммәтләр, гавами һәм шәхси мәнфәгатьләр балансын үтәү зарурлыгына нигезләнергә тиеш.

3.1. Гражданнар А.Н. Болдырева һәм О.М. Серова дәгъва белдерә торган Кагыйдәләр торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак

белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү һәм реализацияләү тәртибен билгели.

Моннан күренгәнчә, Кагыйдәләрдә шул исәптән мөрәҗәгать итүченең сертификат алу өчен тиешле органга гариза белән мөрәҗәгать итү тәртибе, вәкаләтле орган тарафыннан мондый мөрәҗәгатьне карау һәм аның буенча карар кабул итү тәртибе, гражданга, аны алу хокукын таныган очракта, сертификат бирү тәртибе, ягъни күпбалалы гаиләнең торак шартларын яхшыртуга хокукын гамәлгә ашыру өчен кирәкле процедура гамәлләре тулысынча билгеләнергә тиеш.

Кагыйдәләрнең 12 пунктындагы өченче абзацында каралганча, гражданның сертификат алуга хокукын таныган очракта, җирле үзидарә органы тарафыннан аны сертификат алу өчен гражданнар исемлекләренә кертү турында карар кабул ителә.

Үзенең турыдан-туры эчтәлегеннән чыгып, гражданны сертификат алу өчен гражданнар исемлегенә кертү турындагы карар гражданга торак урыны алу өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидия алу хокукын документаль рәвештә раслый һәм үзенең хокукый мәгънәсе буенча процессуаль акт характерына ия, гражданнар өчен, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләр өчен, нинди дә булса өстәмә бурычлар тудырмый, ә киресенчә, җирле үзидарә органына гражданның күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификат бирү һәм реализацияләү өчен тәкъдим ителә торган таләпләргә туры килүен раслауны йөкли.

Шикаять белдерелә торган норматив хокукый актта мондый карарны рәсмиләштерүгә карата таләпләр күрсәтелмәгәнлектән, ул җирле үзидарә органы тарафыннан аерым документ рәвешендә дә, шулай ук әлеге карарны тиешле торак комиссияләре утырышлары беркетмәләренә кертү юлы белән дә мөстәкыйль рәвештә рәсмиләштерелергә мөмкин.

Кагыйдәләрнең 15 пунктындагы беренче абзацы җирле үзидарә органнары ел саен, 1 октябрьгә кадәр, бу Кагыйдәләргә 1 нче кушымта нигезендә планлаштырыла торган елга гражданнар исемлекләрен

формалаштыралар һәм аларны Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына кертәләр дип билгели.

Күрсәтелгән норма үз карамагында гражданнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә кую һәм аларның сертификат алу хокукын тану булган җирле үзидарә органнары һәм Министрлык арасында үзара хезмәттәшлек тәртибен регламентлаштыра, аның карамагына шул исәптән планлаштырыла торган елда сертификатлар алучы гражданнар исемлеген һәм шул ук елда сертификат алу өчен резервка кертелгән гражданнарның исемлекләрен формалаштыру да керә. Дәгъва белдерелә торган норманы анализлау, ул үзенең максатчан билгеләнеше буенча, мөрәҗәгать итүчеләр ягыннан да, җирле үзидарә органнары һәм Министрлык ягыннан да законсыз гамәлләрне булдырмас өчен, Кагыйдәләрдә билгеләнгән срокларда мәгълүмат тапшыруның нәтиҗәле процедурасын билгеләүгә юнәлдерелгән дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Кагыйдәләрнең 12 пунктындагы өченче абзацы да, 15 пунктындагы беренче абзацы да, гамәлдәге хокукый җайга салу системасында аларның урыныннан чыгып, карала торган социаль ярдәм чарасын бирү тәртибен тиешле дәрәҗәдә тәэмин итүгә юнәлдерелгән һәм, чынбарлык һәм адреслылык принципларына нигезләнеп, максаты күпбалалы гаиләне сертификат алу өчен гражданнар исемлекләренә кертү турында тиешле карарлар кабул итү һәм планлаштырыла торган елга гражданнар исемлекләрен формалаштыру өчен җаваплы затларның гамәлләренең алгоритмын ачыклау булган гомуми күрсәтмәләрне билгели.

Димәк, Кагыйдәләрнең 12 пунктындагы өченче абзацының һәм 15 пунктындагы беренче абзацының хокукый нигезләмәләре гаилә һәм бала мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән хокукый механизм элементларының берсе булып тора һәм үзеннән-үзе күпбалалы гаиләләрнең конституциячел хокукларын, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләрнең гаиләләренең дә хокукларын юкка чыгара, чикли яисә башкача боза торган буларак карала алмый.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә.

Эшне тыңлау барышында дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле чыгышыннан хокук куллану практикасында барлыкка килгән Кагыйдәләрнең 12 пунктындагы өченче абзацына һәм 15 пунктындагы беренче абзацына аңлатма бирү гражданны сертификат алу өчен гражданнар исемлегенә кертү турында җирле үзидарә органы тарафыннан карар кабул ителгән гражданнар ел саен аларны исемлекләргә кертү турында кабат гариза бирергә бурычлы булуыннан, шулай ук аерым очракларда өстәмә документлар тапшырырга тиешлегеннән килеп чыгуы ачыкланган иде.

Кагыйдәләрнең әлеге нормаларының турыдан-туры эчтәлеген анализлау түбәндәге нәтиҗәне ясарга мөмкинлек бирә: алар үзеннән-үзе сертификат алу хокукына ия булган гражданнарга ел саен җирле үзидарә органнары таләбе буенча нинди дә булса гаризалар һәм өстәмә документлар тапшыру бурычын йөкләми, алар вәкаләтләренә гражданны сертификат алу өчен гражданнар исемлегенә кертү турында карарлар кабул итү керә. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданнардан гаризалар һәм өстәмә документлар таләп итү норматив хокукый акт текстында мондый бурыч турыдан-туры каралган очракта гына мөмкин булуын билгеләп үтәргә кирәк дип саный. Норматив хокукый акт текстында гражданнарның мондый бурычлары булмаганда, мондый хокук куллану практикасы асылда җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен нигезсез киңәйтү турында сөйли һәм гражданнарга шикаять белдерелә торган Кагыйдәләрдә турыдан-туры каралмаган өстәмә вазыйфалар йөкли.

3.2. Кагыйдәләрнең 15 пунктындагы икенче абзацы, 16 пунктындагы икенче абзацы, 17 пунктындагы өченче абзацы гражданнар А.Н. Болдырева һәм О.М. Серова тарафыннан җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы сертификатлар алучы гражданнар һәм сертификат алу өчен резервка кертелгән гражданнарның исемлекләрен гражданнарның бишенче баласы туу вакытына яисә сертификат алу хокукы булган гаиләне тану датасына бәйлелектә түгел, ә гражданнар торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелган шул ук хронологик эзлеклелекне саклап формалаштырган өлешендә дәгъва белдерелә.

Социаль ярдәм чараларын бирү мәсьәләсендә хокукый мөнәсәбәтләр үзенчәлеге аларны җайга салуның мөмкин булган ысулларының күптөрлелегеннән тора, димәк, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты шактый дискрециягә ия, ләкин ул тигезлек, гаделлек һәм башка конституциячел принциплар белән чикләнгән, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрнең ихтыяҗларын мөмкин кадәр күбрәк канәгатьләндерерлек шундый хокукый җайга салу ысулын сайлауга омтылырга тиеш. Субсидиянең максатчан билгеләнешен, бишенче бала тууны һәм шуңа ярашлы рәвештә, моңа мөрәҗәгать итүчеләр күрсәткәнчә, мондый гаилә тарафыннан сертификат алу хокукын тану датасын исәпкә алып, күпбалалы гаиләләргә аны бирү мәсьәләсендә һичшиксез мөһим һәм әһәмиятле шартлар булып торалар. Шул ук вакытта, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм тиешле исәпкә куелган, дәүләт ярдәменә мохтаҗ күпбалалы гаиләнең шулай ук көтү дәвамлылыгы да мөһим шарт булып тора.

Шикаять белдерелә торган Кагыйдәләрдән күренгәнчә, торак урыны алу өчен субсидия бирү рәвешендәге социаль ярдәм чарасы Татарстан Республикасы тарафыннан үзенә караган дискрет вәкаләтләр кысаларында үзеннән-үзе күпбалалы гаиләләргә түгел, ә торак законнарының гомуми нормалары нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган күпбалалы гаиләләргә генә бирелгән.

Россия Федерациясе Торак кодексының 57 статьясындагы 1 өлеше, торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә торучы гражданнарга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибен беркетеп, торак урыннарын, мондый гражданнарны исәпкә алу вакытыннан чыгып, чиратлылык тәртибендә бирү турындагы гомуми кагыйдәне билгели.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 мартындагы 153 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын арзан һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм аларны гамәлгә ашыру кагыйдәләре, шулай ук сертификат алырга теләүче гражданнарның исемлекләрен һәм мондый гражданнарның җыелма исемлеген төзү ярдәмче программада катнашучы гражданнар торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелган вакытка бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла дип билгели. Бу чакта җыелма исемлек гражданнарның һәр категориясе буенча ярдәмче программада катнашучы гражданнар торак урыннарга мохтаҗлар буларак нинди хронологик эзлеклелектә исәпкә куелган булсалар, шул рәвешчә төзелә (Кагыйдәләрнең 24, 26 пунктлары).

Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъва белдерелә торган Кагыйдәләрнең хокукый нигезләмәләре федераль законнар белән охшашлык буенча күпбалалы гаиләне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә кую датасына бәйле рәвештә гражданнарның җыелма исемлеген, сертификат алучы гражданнарның һәм сертификат алу өчен резервка кертелгән гражданнарның исемлекләрен формалаштыруның хронологик тәртибен беркетәләр.

Димәк, торак сертификатын бирү чиратын гражданны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую вакытыннан чыгып билгеләү гаделлек, тигезлек һәм адреслылык принципларына җавап бирә, чөнки нәкъ менә озак

вакытлар канәгатьләнерлек булмаган торак шартларында яшәгән гаиләләргә социаль ярдәм чараларын бирүне күздә тота.

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә туры килә, ул берничә тапкыр күрсәткәнчә, гаделлек, тигезлек һәм ярашканлык конституциячел принципларыннан закон чыгаручыга юнәлтелгән бер үк категориягә караган затларның хокукый хәлендә объектив һәм акылга ярашлы аклануга ия булмаган аерымлыклар кертүне тыю (бер үк яки охшаш хәлләрдә булган затлар белән төрлечә эш итүне тыю) килеп чыга. Хокукый җайга салуның теге яисә бу өлкәсендә гражданнарның хокукларындагы аермаларга китерә торган теләсә нинди дифференциация Россия Федерациясе Конституциясе, шул исәптән аның 17 (3 өлеш), 19 (1 һәм 2 өлешләр) һәм 55 (3 өлеш) статьялары таләпләренә җавап бирергә тиеш, әгәр алар объектив акланган, нигезләнгән һәм конституциячел әһәмиятле максатларга туры килсә генә рөхсәт ителә, ә әлеге максатларга ирешү өчен кулланыла торган хокукый чаралар шуларга тиң (2001 елның 24 маендагы 8-П номерлы, 2007 елның 5 апрелендәге 5-П номерлы, 2010 елның 3 февралендәге 3-П номерлы, 2012 елның 27 февралендәге 3-П номерлы, 2019 елның 22 мартындагы 15-П номерлы һәм башка карарлар).

Балалар тәрбияләүче гаиләләрне нигезсез балалар һәм гомумән гаиләгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән ташламалардан файдалану турындагы мәсьәләләрдә тигез булмаган хәлгә куя торган аермаларны билгеләү ярамаганлыгына Кеше хокуклары буенча Европа Суды да күрсәтте («Веллер (Weller) Венгриягә каршы» эше буенча 2009 елның 31 мартындагы Карар).

Шул ук вакытта хокукый җайга салуда ачык, ике төрле аңлашылмый торган биш һәм аннан да күбрәк баласы булган һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чараларын билгеләү тәртибен беркетү зур хокукый әһәмияткә ия. «Күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшырту буенча өстәмә чаралар турында» 2001 елның 17 мартындагы 216-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән ата-аналары белән бергә яшәүче һәм үз гаиләләрен кормаган биш һәм

аннан күбрәк баласы булган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләр торак урыннарын чираттан тыш алу хокукына ия граждannар категориясенә керә дип билгеләнгән. Татарстан Республикасы Конституция суды 2011 елның 5 октябрендәге 44-П номерлы һәм 2013 елның 10 июлендәге 54-П номерлы карарларында күпбалалы гаиләләр күрсәтелгән торак субсидиясеннән файдаланыргамы яисә торак урынын Татарстан Республикасы Президентының югарыда күрсәтелгән Указында каралган рәвештә чиратсыз алу хокукын саклап калыргамы дигән мәсьәләдә сайлау хокукына ия дип билгеләде. Татарстан Республикасы Президентының әлеге Указы үз көчен саклый, шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды гавами хакимият органнарының игътибарын күпбалалы гаиләләрнең натуралата торак урынын чираттан тыш алу хокукын гамәлгә ашыру тәртибенең кабул ителмәвенә юнәлтергә кирәк дип саный, шуңа бәйле рәвештә әлеге хокук иллюзор характерга ия, бу хокукый дәүләтнең конституциячел принципларына туры килми һәм тиешле хокукый җайга салуны гамәлгә ашырганда рөхсәт ителми.

Дәгъва белдерелә торган Кагыйдәләрдә мохтаҗлыкның, мәсәлән, гаиләнең аерым әгъзасына туры килә торган торак урынның гомуми мәйданы һәм бишенче бала туган вакытта гаиләнең керем дәрәҗәсе кебек өстәмә критерийлары каралмаганлыгы турында граждannар А.Н. Болдырева һәм О.М. Серова дәлилләренә карата, Татарстан Республикасы Конституция суды, шикаять белдерелә торган нормаларга карата, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлык һәм гражданның торак шартларын яхшыртуга хокук бирүче керемен билгеләү критерийлары торак законнары нормаларыннан чыгып билгеләнүен исәпкә алып, мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан күрсәтелгән критерийлар граждannарның күрсәтелгән категориясе өчен торак сертификатларын бирү тәртибен башка хокукый җайга салуны гамәлгә ашыру өчен нигез була алмый дип билгеләп үтә.

Моннан күренгәнчә, Кагыйдәләрнең 15 пунктындагы икенче абзацы, 16 пунктындагы икенче абзацы, 17 пунктындагы өченче абзацы җирле үзидарә

органнары һәм Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы сертификатлар алучы гражданнар һәм сертификат алу өчен резервка кертелгән гражданнарның исемлекләрен гражданнар торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелган шул ук хронологик эзлеклелекне саклап формалаштырган өлешендә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә.

4. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъва белдерелә торган Кагыйдәләрнең хокукый нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану күпбалалы гаиләләргә торак шартларын яхшырту өчен субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын камилләштерүгә комачауламый.

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты, 49 статьясындагы 2 өлеше һәм 57 статьясындагы 2 өлешенең 3 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре эчтәлегеннән күренгәнчә, әлеге Кодексның 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче гражданнар, аларны аз керемлеләр дип таныган һәм торак законнарында каралган тәртиптә алар тарафыннан торак урынына мохтаҗлыклары расланган очракта, социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннары чираттан тыш бирелү хокукына ия.

Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле органы тарафыннан расланган гражданнарның бер фатирда бергә яшәве мөмкин булмаган авыр хроник авырулар исемлегендә күрсәтелгән авырулардан интегүче балигъ булмаган балалар, аерым алганда инвалид балалар, бигрәк тә аларга камилләшкән үсеш һәм җәмгыятькә интеграцияләнү өчен шартлар тәэмин ителүенә мохтаҗ. Бу максатларда инвалидлар катнашында иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны гамәлгә ашырганда, югары социаль яклауга мохтаҗ затлар буларак, аларның мәнфәгатьләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алырга кирәк, бу инвалидларга өстәмә өстенлекләр һәм конституциячел хокукларны гамәлгә

ашырганда башка гражданнар белән тигез хокукны гарантияләүче мөмкинлекләр бирә торган махсус хокукый механизмнар булдыруны гына түгел, югары психологик һәм эмоциональ йөкләмәләр, физик һәм матди чыгымнар белән бәйле инвалид балаларны тәрбияләү һәм аларны карау буенча социаль әһәмиятле функцияне гамәлгә ашыручы затлар өчен мондый затларга инвалид балаларның яше һәм сәламәтлеге торышына бәйле аларның аерым мохтаҗлыкларын һәм ихтыяҗларын тәэмин итү зарурлыгы белән бәйле барлыкка килә торган тиешле мәшәкатьләрне билгеле бер рәвештә компенсацияләү өчен социаль ярдәм чараларын кертүне дә күздә тота (2018 елның 22 гыйнварындагы 4-П номерлы Карар).

Шуңа бәйле рәвештә, составында югарыда аталган Исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авыру белән интегүче граждан булган биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләгә торак урыны алу өчен субсидияләрне чираттан тыш тәртиптә бирү социаль хокукый дәүләтнең асылына җавап бирер иде һәм социаль ярдәм чараларын күрсәтүгә аеруча мохтаҗ гражданнарның мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итәр иде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 12 пунктындагы өченче абзацын, 15 пунктын, 16 пунктындагы икенче абзацын һәм 17 пунктындагы өченче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазифаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 90-П**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**